РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12.09.2020 Буа шәһәре № 364/ИК-п

ТР Буа муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 08 сентябрендәге 405 - п номерлы карары белән расланган, 2017-2020 елларга хокук бозуларны профилактикалау буенча ТР Буа муниципаль районының комплекслы программасына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Татарстан Республикасы территориясендә корал, сугыш кирәк-яраклары, кораллануга патроннар, шартлаткыч җайланмалар һәм шартлаткыч матдәләрнең законсыз әйләнешен кисәтү чаралары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 05.08.1995 номерлы карары нигезендә, шулай ук 2017 - 2020 елларга хокук бозуларны профилактикалау буенча Буа муниципаль районы комплекслы программасының программа чаралары исемлегенә үзгәрешләр кертү зарурлыгына бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 08 сентябрендәге 405 - п номерлы «2017-2020 елларга хокук бозуларны профилактикалау буенча Буа муниципаль районының комплекслы программасын раслау турында» карары белән расланган, 2017-2020 елларга хокук бозуларны профилактикалау буенча Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының комплекслы программасына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 6 бүлекне 4.22 пункты белән кушымтада бирелгән редакциядә тулылыандырырга.

2. Әлеге карар рәсми бастырылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп тотуны үз өстемә йөклим.

Башкарма комитет җитәкчесе
вазыйфасын башкаручы И.Г. Гыйззәтов

Кушымта

| Төп чаралар исеме | Башкаручылар | Төп чараларны башкару сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның билгеләнеше | Җирле бюджет исәбеннән финанслау |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2020 ел | 2020 ел |
| 4.22 Законсыз саклanган яки табылган корал, сугыш припаслары, коралга патроннар, шартлаткыч җайланмалар һәм шартлаткыч матдәләрне ирекле рәвештә тапшырган өчен акчалата түләү турында карар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү | Буа муниципаль районы Башкарма комитеты, Эчке эшләр министрлыгы бүлеге, "Юл хәрәкәте иминлеге" республика дәүләт унитар предприятиесе | 2020 ел | | – | – |